“Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф идарәсе” муниципаль казна учреждениесе

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы
“Азнакай шәһәре балалар иҗат үзәге”

| | |
|---|---|
| Педагогик совет утырышында<br>каралды һәм кабул ителде<br>Беркетмә № 1<br>“07” 09 2021 ел. | ГАМӘЛГӘ КЕРТЕЛДЕ<br>07.09.2021 приказ № 133<br>Директор: ӨББМБО “Азнакай шәһәре БИҮ”<br>Р.М Хасанова<br>“07” 09. 2021 ел. |

# " Әдәби туган як"өстәмә гомуми белем бирү, гомумүсеш программасы

Юнәлеш: туристлык – туган төбәкне өйрәнү
Укучыларның яше: 12 -15 яшьлекләр өчен
Гамәлгә ашыру вакыты: 2 ел (360 сәгать)

Автор-төзүче:
Кашапова Фирүзә Фәнил кызы,
өстәмә белем бирү педагогы

Азнакай шәһәре, 2020

Эчтәлек

1.Аңлатма язуы_________________________________________3- 6 бит

2.Уку-укыту тематик планы________________________________7-16 бит

3.Программаның эчтәлеге_________________________________17-19 бит

4. Планлаштырылган нәтиҗәләр____________________________20 бит

5. Программаны тормышка ашыруның оештыру-педагогик шартлары

____________________________________________________________21-23 бит

6. Аттестацияләү формалары/контроль һәм бәяләү материаллары__24 бит

7.Әдәбият исемлеге_______________________________________25 - 26 бит

## 1 нче бүлек Аңлатма язуы

Программаның юнәлеше – **туристлык – туган төбәкне өйрәнү**
Әлеге программа укучыларда туган як тарихы, мәдәнияте, әдәбият - сәнгате буенча белемнәр формалаштырырга мөмкинлек бирә. Туган як тарихын өйрәнү халыкның иҗади көчен, гореф-гадәтләрен һәм игелекле традицияләрен тулысынча өйрәнүне күздә тота.Укучылар үзләре яши торган төбәкнең традицияләрен, халкын, тарихын, мәдәниятен, табигатен, аның үзенчәлекләрен эзләнү – тикшеренү эшләре аша ачыклыйлар; үз халкының рухи байлыгын өйрәнеп, аны үстерү һәм саклау өчен үзләреннән өлеш кертүгә омтылалар; туган як белән кызыксынулары аша аңа мәхәббәт, туган ягыбыздан чыккан әдипләр, күренекле кешеләр белән горурлану хисләре тәрбияләнә.
**“ӘДӘБИ ТУГАН ЯК”** өстәмә гомуми белем бирү программасы түбәндәгеләрне исәпкә алып төзелде :
1. "Россия Федерациясендә Мәгариф турында" 29.12.2012 чыккан № 273 - ФЗ Федераль законы;

2. Балаларга өстәмә белем бирү үсеш концепциясе (4 нче сентябрь 2014 нче елда чыккан, № 1726-р РФ Хөкүмәте карары );

3. “Мәгариф” милли проекты кысаларында “Һәр баланың уңышы” федераль проекты. РФ Президенты каршындагы Стратегик үсеш һәм милли проектлар советы президиумның 2018 елның 3 сентябрендә 10 номерлы утырыш беркетмәсе белән расланган.

4. Россия Мәгариф министрлыгының “Балаларга өстәмә белем бирүнең төбәк системаларын үстерүнең максатчан моделен раслау турында” 2009 елның 3 сентябрендәге 467 номерлы боерыгы.

5. Россия Федерациясе Мәгариф Министрлыгының “Өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында” 2018 елның 9 ноябрендәге 196 номерлы боерык

6. РФ Мәгариф һәм фән Министрлыгының “Белем бирү эшчәнлеген, электрон белем бирүне, белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда дистанцион белем бирү технологияләрен гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан куллану тәртибен раслау турында” 2017 елның 23 августындагы 816 номерлы боерык»

7. "СанПиН 2.4.4.3172 -14 "Балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында эш оештыру төзелеше, эчтәлеге һәм режимына куела торган санитария-эпидемиология таләпләре " РФ дәүләт баш санитария табибының 04.07.2014 чыккан 41 нче номерлы карары.

“Әдәби туган як” өйрәнү түгәрәгендә шөгыльләнгән бала:

- үз гаиләсе тарихына хөрмәт белән карый, горурлану хисләре кичерә;
- мөстәкыйль рәвештә ачышлар ясый;
- материал җыя, гомумиләштерә, мәктәп музеен тулыландыра;
-эзләнү эше алып бара, материалны анализлый, системалаштыра, гомумиләштереп, нәтиҗәләр ясый;
- уеннар вакытында өйрәнгән материалны ныгыта;
- туган як әдәбияты, тарихы буенча белемнәрен арттыра;
- фәнни-тикшеренү эшләренә өйрәнә;
- үз – үзендә патриотизм, туган якка мәхәббәт хисе тәрбияли;
- туган төбәгенең тарихына, әдәбиятына, сәнгатенә бәйле күренекле шәхесләре белән горурлана.

**Программаның актуальлеге:** Бүгенге җәмгыятьтә укытучы алдында гаять зур бурычлар тора. Конкуренциягә сәләтле, заман таләпләреннән чыгып эш итә белә торган, рухи һәм физик яктан камил шәхес тәрбияләү – иң төп максатыбыз. Ә ул үз чиратында , туган телебезне яратучы, үз милләтенең мәдәниятен, иң күркәм йолаларын, гореф-гадәтләрен, тарихын хөрмәт итүче булырга тиеш. Зыялылык, ватанпәрвәрлек кебек сыйфатлар үзеңнең туган ягыңны, аның тарихын, кешеләрен яхшы белгәндә генә формалаша ала. Туган якны яратырга өйрәтү, туган якка мәхәббәт тәрбияләү, туган як тарихын өйрәнү - патриотик тәрбия бирүнең иң отышлы ысуллары. Туган як тарихы ул - шунда яшәгән кешеләр тарихы. Кешенең тарихта тамырлары гаиләсенең традицияләрендә, халкының, туган ягының үткәнендә. Туган як тарихын өйрәнү укучыларга үз төбәкләрендә яшәгән кешеләр турында күбрәк белергә, якыннан танышырга мөмкинлек бирә.

Патриотик тәрбия бирүдә тагын мөһим чараларның берсе - музейлардагы хәзинәне - тарихи экспонатларны, халкыбызның рухи һәм матди культурасын, бүгенгесен һәм узганын чагылдыручы кыйммәтле материалларны куллану. Укучыларда туган илгә мәхәббәт, халкыбызның үткәндәге истәлекләрен хөрмәт итү, хәзерге казанышларына ихтирам һәм горурлык хисләре, милли аң тәрбияләүдә, укучыларга патриотик тәрбия бирүдә мәктәп музейлары зур әһәмияткә ия. Музей шулай ук туган якның , туган авылның , туган мәктәпнең тарихын өйрәнү, аны буыннан буынга саклап калдыруда һәм укыту-тәрбия эшендә зур ярдәмче. Музейда үткәрелгән очрашулар, экскурсия, дәресләр , туган якка кагылышлы җирле материалларны өйрәтү аша балалар күңеленә патриотизм орлыклары салына. Мәктәптә үткәрелгән әдәби кичәләр - укучыларга чын-чынлап илһам чыганагы. Балаларга алдагы буыннарның бай тормыш тәҗрибәсен өйрәтү, тарихы, гореф-гадәтләре, йолалары белән таныштыру кебек максатларга ирешү өчен музей материаллары - чиксез бай хәзинә.

Туган як тарихын өйрәнү халыкның иҗади көчен, гореф-гадәтләрен һәм игелекле традицияләрен тулысынча өйрәнүне күздә тота. Укучы үзе яши торган төбәкнең традицияләрен, халкын, тарихын, мәдәниятен, табигатен, аның үзенчәлекләрен аеруча яхшы белергә тиеш.

Түгәрәк эшчәнлеге укучыларны халкыбызның рухи - әхлакый идеалларына китерергә, аларда сөйләм культурасы формалаштырырга, иҗади сәләтен үстерергә, мөстәкыйль уйларга һәм эшләргә омтылышын канәгатьләндерү юнәлешендә дә эш алып бара. Түгәрәктә танып - белү эшчәнлеге аралашу формасында оештырыла. Укучылар түгәрәктә газета - журналлар басу технологиясе, газета әсәрләре иҗат итүнең

баскычлары (тема табу, фактлар туплау, әңгәмә үткәрү, текст төзү, ритм, рифма һ.б.), журналистика жанрлары турында да мәгълүмат алалар. Үзләре газета - журналлар өчен шигырьләр, хикәяләр, мәкаләләр иҗат итәләр, үзләре язган шигырьләрне сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнәләр.

Программаның актуальлеге укучыларда туган як тарихы, мәдәнияте,әдәбият - сәнгате буенча белемнәр формалаштыру кирәклеге һәм куелган максат, бурычлардан чыгып билгеләнә.

**Программаның аерылып торучы үзенчәлекләре:** тарихны сөйләп кенә бала күңеленә сеңдереп булмый.Бала эшчәнлеккә үзе катнашканда гына , үз күзләре белән күреп, үз куллары белән тотып караганда гына үзе өчен ачышлар ясый һәм белмәгәннәрен бүтәннәргә җиткерә ала. Эзләнү – тикшеренү эшләре аша, калган укучыларга да туган ягыбызның тарихын җиткерү, халкыбызның мәдәнияте, әдәбияты, сәнгате белән кызыксындыруга ирешү.

**Программаның адресаты:** 12-15 яшьлек укучылар.

**Программаны үзләштерү вакыты, дәресләр үткәрү режимы, периодлылыгы, дәвамлылыгы:** "Әдәби туган як" өстәмә белем бирү программасы 2 елга исәпләнә. Уку планыныда атнага 2 тапкыр 2 сәг. Барлыгы 144 сәгать беренче уку елында, атнага 3 тапкыр 2 сәг. - 216 сәгать икенче уку елында.

**Дәресләрне үткәрү формалары:** практик, мөстәкыйль һәм иҗади эшләр, интеллектуаль уеннар, эзләнү – тикшеренү эшләре, экскурсияләр, әдәби кичәләр.

Укучыларда кызыксыну уяту өчен һәр дәрестә иҗадилык һәм эзләнү элементларын кертү.

Теоретик һәм практик эшләрне чиратлаштыру.

Дәресләр берләшмәнең барлык катнашучылары белән дә, укучылар төркеме белән дә аерым тема буенча яки конкурс эшләрен, тикшеренү эшләрен, проектларны әзерләгәндә шәхси консультацияләр рәвешендә һ.б. уза ала. Моннан тыш, фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашырга әзерләнү өчен сәләтле балалар белән индивидуаль дәресләр үткәрү күздә тотыла.

"Азнакай шәһәре балалар иҗат үзәге" өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы һәм «Азнакай шәһәре 7 нче урта гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе арасында төзелгән үзара хезмәттәшлек турында шартнамә нигезендә, кирәк булганда, «Азнакай шәһәре 7 нче урта гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе базасында дәресләр үткәрелергә мөмкин.

**Укыту формасы:** көндезге. Программаны яисә аның өлешләрен гамәлгә ашырганда, уку дәресләре, практикалар үткәргәндә, электрон белем бирү, укучыларның өлгерешен агымдагы контрольдә тоту, арадаш аттестацияләү кулланылырга мөмкин.

**Оештыру үзенчәлекләре:** 12-15 яшьлек укучыларның даими группасы.

**"Әдәби туган як" түгәрәгенең максаты**: үз халкының рухи байлыгын өйрәнү, аны үстерү һәм саклау өчен үзләреннән өлеш кертүгә омтылыш тәрбияләү; укучыларда

эзләнү-тикшеренү, материалны системага салу күнекмәләре формалаштыру; туган як белән кызыксынуларын үстерү һәм аңа мәхәббәт,туган ягыбыздан чыккан әдипләр, күренекле кешеләр белән кызыксыну һәм алар белән горурлану хисләре тәрбияләү.

Максатка ирешү өчен **түбәндәге <u>бурычларны</u>** хәл итү күздә тотыла:

*Уку – укыту:*

- туган як тарихын, әдәбиятын, сәнгатен, аларга бәйле шәхесләрне, мәгариф һәм сәнгать тарихын эзлекле өйрәнү;
- укучыларда эзләнү-тикшеренү, материалны системага салу күнекмәләре булдыруга ихтыяҗ тудыру;
- туган төбәгебез турында алган белемнәрне тирәнәйтү һәм камилләштерү.
- түгәрәк әгъзалары тарафыннан уңышлы дип табылган әсәрләрне республикада чыгып килә торган газета - журналга тәкъдим итү;

- *Тәрбияви:*
- укучыларда милли үзаң формалаштыру;
- туган төбәгебезгә мәхәббәт,туган ягыбыздан чыккан әдипләр, күренекле кешеләр белән кызыксыну һәм алар белән горурлану хисләре тәрбияләү.

- *Үстерелешле:*
- укучыларга үзләренең нәсел тамырларына, үз гаиләләренең үткәненә кызыксыну уяту;
- туган төбәгебезнең истәлекле урыннарына, җөмһүриятебезнең тарихи шәһәрләренә, табигатькә экскурсияләр үткәрү;
- мөстәкыйль рәвештә эзләнү – тикшеренү һәм иҗади эшләргә рухландыру.
- төрле бәйгеләрдә катнашу, укучыларның буш вакытларын файдалы итеп үткәрүгә ирешү.

## 2 нче бүлек Уку-укыту тематик планы

### Беренче уку елына укыту- тематик план

| № | Тема | Сәгать саны | | | Аттестация формасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | теория | практика | |
| | ***I бүлек. Мин һәм минем гаиләм ( 9 сәгать)*** | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | **1.** “Әдәби туган як” түгәрәгендә техника куркынычсызлыгы һәм үз – үзеңне тоту кагыйдәләре.<br>Үз нәселеңне беләсеңме?- гаилә тарихын өйрәнү | 2 | 2 | | |
| 2 | **2.** Хатлар ни сөйли? | 2 | | 2 | |
| 3 | **3.** Нәселем шәҗәрәсе | 2 | | 2 | |
| 4 | **4.** Нәселемнең укымышлы кешеләре. Нәселемнең озын гомерле кешеләре | 2 | | 2 | |
| 5 | **5.** Нәселем традицияләре | 2 | | 2 | |
| 6 | **6.** Һәр буынга сыйфатлама-характеристика язу | 2 | | 2 | |
| 7 | **7.** “Шәҗәрәдә гаиләм тарихы” | 2 | | 2 | ***шәҗәрәләр күргәзмәсе*** |
| 8 | **8.** Нәсел агачын төзү үрнәкләре | 2 | | 2 | |
| 9 | **9.** Нәсел агачын төзү (үз гаиләң үрнәгендә) | 2 | | 2 | |
| | ***II бүлек. Туган ягым – Азнакаем (19 сәгать)*** | | | | |
| 10 | **10.** Азнакаем тарихы | 2 | 2 | | |
| 11 | **11.** Азнакаемның исеме каян килеп чыккан? | | | | |
| 12 | **12.** Азнакаемдагы географик атамалар һәм аларның тарихы (Өлкән кешеләр белән очрашып язып алу) | 2 | | 2 | |
| 13 | **13.** Азнакай кешеләренең культурасы һәм көнкүреше(җырлар, бәетләр). | 2 | | 2 | |
| 14 | **14.** Туган ягым һөнәрләре һәм һөнәрчеләре . Мәктәп музеена экскурсия | 2 | | 2 | |
| 15 | **15.** Азнакай тарихы . Мәктәп музеена экскурсия | 2 | | 2 | |
| 16 | **16.** Туган ягымдагы хезмәт һәм хезмәт кешеләре ( төрле һөнәр ияләре белән очрашу). | 2 | | 2 | |
| 17 | **17.** Туган төбәк кешеләре Бөек Ватан сугышында (ветераннар белән очрашу, өйләрендә булу) | 2 | | 2 | |
| 18 | **18.** Сугыш чоры балалары | 2 | | 2 | |
| 19 | **19.** Алар Ватан алдындагы бурычны үтәделәр (Әфганстанда хәрби хезмәттә булучылар турында сөйләшү) | 2 | | 2 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 20 | **20.** Мәктәп тарихы (Мәктәп музеендагы бүлекләр белән танышу) | 2 | | 2 | |
| 21 | **21.** Мәктәпнең элекке укытучылары (Мәктәп музеендагы экспозиция белән танышу, өстәмә материаллар туплау) | 2 | | 2 | |
| 22 | **22.** Ветеран укытучыларның өйләрендә булу (очрашу) | 2 | | 2 | |
| 23 | **23.** Алар безнең мәктәптә укыдылар (Материаллар туплау, стенд төзү) | 2 | | 2 | |
| 24 | **24.** Шушы яктан, шушы туфрактан без. Күренекле кешеләр белән очрашу үткәрү | 2 | | 2 | *Азнакайның күренекле кешеләре белән танышу* - ***“Илдус Гыйләҗев шигърияте-нең өч та-җы”*** |
| 25 | **25.** “Якты йолдыз булып яна Азнакай күңелемдә” - дәрес- конференция | 2 | | 2 | |
| 26 | **26.** Азнакайның тарихи урыннары.Телдән журнал | 2 | | 2 | |
| 27 | **27.** Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 | | 2 | |
| 28 | **28.** Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 | | 2 | |
| | ***III бүлек. Азнакаем - Чатыр таулы шигъри, җырлы, илһамлы төбәк...(22 сәгать)*** | | | | |
| 29 | **29.** Азнакай районы тарихы *битләреннән. “Азнакай тамчылары”, “Азнакай” китаплары белән танышу* | 2 | | 2 | |
| 30 | **30.** Данлыклы райондашларыбыз. *Телдән журнал.* | 2 | | 2 | |
| 31 | **31.** Данлы Азнакаем минем... *Район үзәгендәге Җиңү паркына, “Дельфин” су- сәламәтләндерү үзәгенә экскурсия.* | 2 | | 2 | |
| 32 | **32.**”*Маяк” газетасы редакциясенә экскурсия.* | 2 | | 2 | |
| 33 | **33.** Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый ! | 2 | | 2 | |
| 34 | **34.** Геройлар аллеясы турында... | 2 | 2 | | |
| 35 | **35.** *Геройлар аллеясы буйлап... (экскурсия)* | 2 | | 2 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 36 | **36.** Районгдагы промышленность предприятиеләре | 2 | 2 | | |
| 37 | **37.** Районыбызның авыл хуҗалыгы | 2 | 2 | | |
| 38 | **38.** Азнакайның сәхнә йолдызлары – күренекле артистлар | 2 | 2 | | |
| 39 | **39.** Туган ягым шагыйрьләре һәм язучылары | 2 | 2 | | |
| 40 | **40.** Туган ягым язучылары | 2 | 2 | | |
| 41 | **41.** Азнакай төбәге җырчылары | 2 | 2 | | |
| 42 | **42.** Данлы Азнакайга – 85 ел... | 2 | 2 | | |
| 43 | **43.** *Районның Туган як музеен экскурсия.* | 2 | | 2 | |
| 44 | **44.** *Батырлар аллеясына, Боз сараена экскурсия.* | 2 | | 2 | |
| 45 | **45.** *Әдәби – музыкаль кичәгә әзерлек “Шушы яктан, шушы туфрактан без”* | 2 | | 2 | |
| 46 | **46.** *Әдәби – музыкаль кичә “Шушы яктан, шушы туфрактан без”* | 2 | | 2 | |
| 47 | **47.** Һөнәр сайлау – җаваплы эш. Туган төбәгебездә дәрәҗәле һөнәрләр (телдән журнал) | 2 | 2 | | **ТЕСТ “Муса Җәлил”** |
| 48 | ***48.** “Дәрәҗәле һөнәр иясе Сез , Без дә Сездән үрнәк алабыз*” (күренекле якташларыбыз - - мактаулы һөнәр ияләре) | 2 | | 2 | |
| 49 | **49.** Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 | | 2 | |
| 50 | **50.** Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 | | 2 | |
| | ***IV бүлек. Татарстан-минем республикам ( 20 сәгать)*** | | | | |
| 51 | 51. ТР тарихы | 2 | 2 | | |
| 52 | **52.** Татарстанның символикасы | 2 | 2 | | |
| 53 | **53.** ТРның географик урыны | 2 | 2 | | |
| 54 | **54.** Татарстанның табигате | 2 | 2 | | |
| 55 | **55.** ТР шәһәрләре. Республика шәһәрләре белән таныштыру. | 2 | 2 | | |
| 56 | **56.** Тарихи шәһәрләргә читтән торып экскурсия ясау. | 2 | 2 | | |
| 57 | **57.** Казан-чал тарихлы башкала. | 2 | 2 | | |
| 58 | **58.** Алабуга - чор - дәверләр капкасы. | 2 | 2 | | |
| 59 | **59.** “И Казан! Серле Казан!” | 2 | 2 | | |

**Икенче уку елына укыту-тематик план**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 60 | **60.** Башкалабыз Казанга багышланган *“Йолдызлы сәгать” уены* | 2 | | 2 | |
| 61 | **61.** Күренекле шәхесләр: язучылар | 2 | 2 | | |
| 62 | **62.** Күренекле шәхесләр: шагыйрьләр | 2 | 2 | | |
| 63 | **63.** Күренекле шәхесләр: җырчылар | 2 | 2 | | |
| 64 | **64.** Күренекле шәхесләр: артистлар | 2 | 2 | | |
| 65 | **65.** Туган җирем – татар телле Татарстан (Туган тел турында...) | 2 | 2 | | |
| 66 | **66.** Туган төбәк, туган җир, туган телебез турында иҗади эшләр дәресе | 2 | | 2 | |
| 67 | **67.** “Татарстан һәм татар халкы тарихы” конкурсы | 2 | | 2 | |
| 68 | **68.** “Газиз дә син, кадерле дә, әй Туган җирем!”- *“Тамчы-шоу” уены* | 2 | | 2 | **Интеллек-туаль бәйге** |
| 69 | **69.** Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 | | 2 | |
| 70 | **70.** Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 | | 2 | |
| 71 | Бүлекне кабатлау | 2 | 2 | | |
| 72 | “Әдәби туган як” курсын йомгаклау | 2 | 2 | | |
| | **Барлыгы 144 сәг.** | | | | |

| № | Тема | Сәгать саны | | | Аттестация формасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Бар-лы-гы | Тео рия | Пр акт ика | |
| ***I бүлек. Мин һәм минем гаиләм ( 18 сәг.)*** | | | | | |
| 1 | “Әдәби туган як” түгәрәгендә техника куркынычсызлыгы һәм үз – үзеңне тоту кагыйдәләре.<br>Үз нәселеңне беләсеңме?-гаилә тарихын өйрәнү | *2* | 2 | | |
| 2 | Хатлар ни сөйли? | *2* | | | |
| 3 | Нәселем шәҗәрәсе | *2* | | *2* | |
| 4 | Нәселемнең укымышлы кешеләре. Нәселемнең озын гомерле кешеләре | *2* | | *2* | |
| 5 | Нәселем традицияләре | *2* | | *2* | |
| 6 | Һәр буынга сыйфатлама-характеристика язу | *2* | | *2* | |
| 7 | “Шәҗәрәдә гаиләм тарихы” | *2* | | *2* | |
| 8 | Нәсел агачын төзү үрнәкләре | *2* | | *2* | |
| 9 | Нәсел агачын төзү (үз гаиләң үрнәгендә) | *2* | | *2* | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| ***II бүлек. Туган ягым–Азнакаем ( 38 сәг)*** | | | | | |
| 10 | Азнакаем тарихы | *2* | | | |
| 11 | Азнакаемның исеме каян килеп чыккан? | *2* | *2* | | |
| 12 | Азнакаемдагы географик атамалар һәм аларның тарихы (Өлкән кешеләр белән очрашып язып алу) | *2* | | *2* | |
| 13 | Азнакай кешеләренең культурасы һәм көнкүреше(җырлар, бәетләр). | *2* | | *2* | |
| 14 | Туган ягым һөнәрләре һәм һөнәрчеләре . Мәктәп музеена экскурсия. | *2* | | *2* | |
| 15 | Азнакай тарихы . Мәктәп музеена экскурсия. | *2* | | *2* | |
| 16 | Туган ягымдагы хезмәт һәм хезмәт кешеләре ( төрле һөнәр ияләре белән очрашу) | *2* | | *2* | |
| 17 | Туган төбәк кешеләре Бөек Ватан сугышында (ветераннар белән очрашу, өйләрендә булу) | *2* | | *2* | |
| 18 | Сугыш чоры балалары | *2* | *2* | | |
| 19 | Алар Ватан алдындагы бурычны үтәделәр (Әфганстанда хәрби хезмәттә булучылар турында сөйләшү) | *2* | | *2* | |
| 20 | Мәктәп тарихы (Мәктәп музеендагы бүлекләр белән танышу) | *2* | | *2* | |
| 21 | Мәктәпнең элекке укытучылары (Мәктәп музеендагы экспозиция белән танышу, өстәмә материаллар туплау) | *2* | | *2* | |
| 22 | Ветеран укытучыларның өйләрендә булу (очрашу) | *2* | | *2* | |
| 23 | Алар безнең мәктәптә укыдылар ( Материаллар туплау, стенд төзү) | *2* | | *2* | |
| 24 | **“**Шушы яктан, шушы туфрактан без” күренекле кешеләр белән очрашу үткәрү. Азнакайның күренекле кешеләре – безнең горурлыгыбыз | *2* | | *2* | |
| **25** | **“Якты йолдыз булып яна Азнакай күңелемдә” - дәрес- конференция** | *2* | | *2* | **дәрес-конференция** |
| 26 | Азнакайның тарихи урыннары.Телдән журнал | *2* | | *2* | |
| 27 | Эзләнү – тикшеренү эшләре. Азнакаебыз турында шигырь-хикәяләр язу | *2* | | *2* | |
| 28 | Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу | *2* | | *2* | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | өчен материаллар туплау | | | | |
| ***Азнакаем - Чатыр таулы шигъри, җырлы, илһамлы төбәк...(44 сәгать)*** | | | | | |
| 29 | Азнакай районы тарихы б*итләреннән. “Азнакай тамчылары”, “Азнакай” китаплары белән танышу* | *2* | | *2* | |
| 30 | Данлыклы райондашларыбыз. *Телдән журнал.* | *2* | | *2* | |
| 31 | Данлы Азнакаем минем... *Район үзәгендәге Җиңү паркына, “Дельфин” су- сәламәтләндерү үзәгенә экскурсия.* | *2* | | *2* | |
| 32 | ”*Маяк” газетасы редакциясенә экскурсия.* | *2* | | *2* | |
| 33 | Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый ! | *2* | | *2* | |
| 34 | Геройлар аллеясы турында... | *2* | ***2*** | | |
| 35 | *Геройлар аллеясы буйлап... (экскурсия)* | *2* | | *2* | |
| 36 | Райондагы промышленность предприятиеләре | *2* | 2 | | |
| 37 | Районыбызның авыл хуҗалыгы | *2* | 2 | | |
| 38 | Азнакайның сәхнә йолдызлары – күренекле артистлар | *2* | 2 | | |
| 39 | Туган ягым шагыйрьләре һәм язучылары | *2* | 2 | | |
| 40 | Туган ягым язучылары | *2* | 2 | | |
| 41 | Азнакай төбәге җырчылары | *2* | 2 | | |
| 42 | Данлы Азнакайга – 86 ел... | *2* | 2 | | |
| 43 | *Районның Туган як музеена экскурсия.* | *2* | | *2* | |
| 44 | *Батырлар аллеясына, Боз сараена экскурсия.* | *2* | | *2* | |
| **45** | *Әдәби кунакханә “Шушы яктан, шушы туфрактан без”* | 2 | | 2 | |
| **46** | *Әдәби кунакханә “Шушы яктан, шушы туфрактан без”* | 2 | | *2* | **Әдәби – музыкаль *кунакханә*** |
| 47 | Һөнәр сайлау – җаваплы эш. Туган төбәгебездә дәрәҗәле һөнәрләр (телдән журнал) | 2 | | 2 | |
| 48 | *“Дәрәҗәле һөнәр иясе Сез , Без дә Сездән үрнәк алабыз*” (күренекле якташларыбыз - мактаулы һөнәр ияләре) | 2 | | *2* | *презентация төзү* |
| 49 | Эзләнү – тикшеренү эшләре, шигырь-хикәяләр язу | 2 | | *2* | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 50 | Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 | | *2* | |
| ***IV бүлек. Татарстан - минем республикам (40 сәгать)*** | | | | | |
| 51 | ТР тарихы | 2 | *2* | | |
| 52 | *Музейга тематик экскурсия “Буыннардан буыннарга күчеп...”* | 2 | | *2* | |
| 53 | Татарстанның символикасы | 2 | 2 | | |
| 54 | ТРның географик урыны | 2 | 2 | | |
| 55 | Татарстанның табигате | 2 | 2 | | |
| 56 | ТР шәһәрләре<br>Республика шәһәрләре белән таныштыру. | 2 | 2 | | |
| 57 | Тарихи шәһәрләргә читтән торып экскурсия ясау. | 2 | *2* | | |
| 58 | Казан-чал тарихлы башкала. | 2 | *2* | | |
| 59 | Алабуга - чор - дәверләр капкасы. | 2 | *2* | | |
| 60 | “И Казан! Серле Казан!” | 2 | *2* | | |
| 61 | Башкалабыз Казанга багышланган *“Йолдызлы сәгать” уены* | 2 | | *2* | |
| 62 | Күренекле шәхесләр: язучылар | 2 | *2* | | |
| 63 | Күренекле шәхесләр: шагыйрьләр | 2 | *2* | | |
| 64 | Күренекле шәхесләр: җырчылар | 2 | *2* | | |
| 65 | Күренекле шәхесләр: артистлар | 2 | *2* | | |
| 66 | Туган җирем – татар телле Татарстан (Туган тел турында...) | 2 | | *2* | |
| 67 | Туган төбәк, туган җир, туган телебез турында иҗади эшләр дәресе | 2 | | *2* | |
| 68 | “Татарстан һәм татар халкы тарихы” конкурсы | 2 | | *2* | |
| **69** | **“Газиз дә син, кадерле дә, әй Туган җирем!”- *““Йолдызлы сәгать” уены*** | *2* | | *2* | ***Интеллек-туаль бәйге*** |
| 70 | Эзләнү – тикшеренү эшләре | *2* | | *2* | |
| 71 | Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | *2* | | *2* | |
| ***Туган төбәгем әдәбияты (34 сәгать)*** | | | | | |
| 72 | Илдус Гыйләҗев – җир шагыйре | *2* | *2* | | |
| 73 | Әдәби сәхифә “Илдус Гыйләҗев шигъриятенең өч таҗы” | *2* | | *2* | |
| 74 | Рөстәм Зәкуан “Җырым туса иде туган җирдә...” | *2* | *2* | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 75 | Марсель Галиев – Чатыр тау данын еракларга яңгыраткан якташ язучыбыз | *2* | *2* | | |
| 76 | Нур Әхмәдиев – шагыйрь һәм прозаик | *2* | *2* | | |
| 77 | Фәүзия Төхвәтуллина | *2* | *2* | | |
| 78 | Флёра Гыйззәтуллина шигырьләре – “тормышның үз авазы” | *2* | *2* | | |
| 79 | Резедә Шәрипова – яраткан шагыйрәбез | *2* | *2* | | |
| 80 | Әнәс Кари –кыска иҗат гомерен балалар әдәбиятына багышлаган шагыйрь | *2* | *2* | | |
| 81 | Галия Сәетшина – авылга дан җырлаучы якташыбыз | *2* | *2* | | |
| 82 | Сәрвәр Хәнипова – туган җирнең матурлыгына, аның халкына дан җырлаучы укытучы-шагыйрә | *2* | *2* | | |
| 83 | Илмира Сәлахова – балачак шагыйрәсе | *2* | *2* | | |
| 84 | Экскурсоводлар белән индивидуаль эш. | *2* | | *2* | |
| 85 | Туган төбәгебез шагыйрь – язучылары турында проектлар төзү, яклау | *2* | | *2* | |
| 86 | “Без шигырь яратабыз” шигырьләр уку бәйгесе | *2* | | *2* | |
| 87 | Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | *2* | | *2* | |
| ***Татар халкының бәйрәмнәре ( 12 сәгать)*** | | | | | |
| 88 | Татар халкының бәйрәмнәре | *2* | 2 | | |
| 89 | Дини бәйрәмнәр | *2* | 2 | | |
| 90 | Сабантуй- хезмәт туе | *2* | | *2* | |
| 91 | Ел фасылларына бәйле милли бәйрәмнәр, йолалар, гореф-гадәтләр | *2* | *2* | | |
| 92 | “Нәүрүз” бәйрәме | *2* | | *2* | |
| 93 | Милли киемнәр. Татар хатын-кызларының милли киеме. Ир-атларның милли киеме. Милли киемнәрнең бизәлеше, төсләре. | *2* | *2* | | |
| ***Шигырь язарга өйрәнәбез (10 сәгать)*** | | | | | |
| 94 | Шигырьдә ритм һәм рифма саклау кагыйдәләре<br>Күренекле шагыйрьләрнең шигырьләрен уку, шигырь төзелешен тикшерү. | *2* | | *2* | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 95 | Газета - журналларда басылган шигырьләргә күзәтү<br>Төрле темаларга шигырьләр иҗат итү, аларны утырышларда уку, анализлау, әдәби тәнкыйть ясау. | *2* | | *2* | |
| **96** | **“Без –Тукай оныклары”** | *2* | | *2* | ***“Тамчы-шоу” уен - бәйге*** |
| 97 | 2019 нчы ел Тукай премиясе лауреатлары | *2* | *2* | | |
| ***Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый... ( 8 сәгать )*** | | | | | |
| 98 | Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый... (БВС ның 74 елллыгы ) – шәһәребезнең Җиңү паркына, Җиңү мәйданындагы  мәңгелек ут монументына экскурсия | *2* | | *2* | |
| 99 | Экскурсоводлар белән индивидуаль эш. | *2* | | *2* | |
| 100 | “Үлемсез полк” акциясендә катнашуга әзерлек, катнашу | *2* | | *2* | |
| ***Газета-журнал укый беләбезме? (18 сәгать)*** | | | | | |
| 101 | Газета ничек ясала?<br>“МАЯК” газетасы редакциясенә экскурсия | *2* | | *2* | |
| 102 | Хәбәрчегә хас сыйфатлар<br>Минем яраткан газетам | *2* | *2* | | |
| 103 | Газета алдаганны яратмый. Газеталарга күзәтүләр | *2* | | | |
| 104 | *Хәбәри жанрлар:*<br>Хәбәр язарга өйрәнәбез. Мәктәптә булган вакыйга яки факт турында язу | *2* | | *2* | |
| 105 | Репортаж-күзәтче жанр. Очрашулар, бәйрәмнәрдән репортажлар язу | *2* | | *2* | |
| 106 | *Аналитик жанрлар:*<br>Корреспонденция- җәмәгатьчелек игътибарын проблемага юнәлтә | *2* | *2* | | |
| 107 | Мәкалә һәм аның төрләре: үтенеч, сорау, информация, бәяләмә, рәхмәт | *2* | *2* | | |
| 108 | Түгәрәк эшенә еллык йомгак. Иң актив укучыларны билгеләү. Мактау кәгазьләре тапшыру | *2* | | *2* | |
| **Барлыгы   216 сәг.** | | | | | |

**3 нче бүлек Программаның эчтәлеге Укыту - тематик планның эчтәлеге (1 нче уку елы)**

**I бүлек. Мин һәм минем гаиләм ( 9 сәгать)**

**<u>Теория:</u>** Гаилә тарихын өйрәнү.Шәҗәрә турында аңлатма.Нәсел шәҗәрәләренең ерак тарихыбызны өйрәнү өчен мөһим чыганак булуы. **<u>Практика:</u>** Шәҗәрә төзү үрнәкләре. Нәселнең географиясе, нәсел башлыгын эзләп табу. Гаиләдә электән сакланган хатларны туплау, хатлардагы мәгълүматларны файдалану. Нәселнең шөгыльләрен, һөнәрләрен өйрәнү.Укымышлы һәм озын гомерле кешеләре турында мәгълүмат җыю. Гаилә традицияләре һәм аларны саклау. Һәр буынга сыйфатлама-характеристика язу -"Минем шәҗәрәм". *"Шәҗәрәдә - гаиләм тарихы"-* ***шәҗәрәләр күргәзмәсе****. Нәсел агачын төзү үрнәкләре.*

**II. Туган ягым – Азнакаем ( 19 сәгать)**

**<u>Теория:</u>** Азнакайга нигез салыну. Исеме, риваятьләре, мәйданы, географик урыны, халкы, сулыклары, истәлекле урыннары, атамалары, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы белән танышу. Туган төбәк кешеләренең культурасы, гореф-гадәтләре.

**<u>Практика:</u>** Бәет, җырлар чыгаручы кешеләр белән очрашу. Һөнәрчеләр һәм аларның һөнәрләре турында мәгълүмат җыю, кул эшләреннән күргәзмә әзерләү,видеотасмага төшерү. Төрле оешмаларның тарихы. Хезмәт кешеләренең тормышын өйрәнү, төрле һөнәр ияләре белән очрашулар үткәрү. Бөек Җиңүнең 73 еллыгы уңаеннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш чоры балалары турында материаллар туплау, өйләрендә булу. Фәнни-тикшеренү эшләре башкару. Әфганстанда хәрби хезмәттә булучылар турында мәгълүмат туплауны дәвам итү. Мәктәп тарихын өйрәнү, ветеран укытучылар , чыгарылыш укучылары белән очрашулар үткәрү, мәктәп тарихын язуны дәвам итү күздә тотыла. Мәктәп музеена экскурсия. Төбәгебездәге күренекле кешеләрнең тормышларын өйрәнү, кылган гамәлләрен хөрмәтләү, яшь буынны шулар үрнәгендә тәрбияләү. *Истәлекле урыннарга сәяхәт.Чишмәләр,су буйларын күзәтү.*

**III. Азнакаем-Чатыр таулы шигъри, илһамлы төбәк...(22 сәг.)**

**<u>Теория:</u>** Районыбыз тарихы, мәйданы, авыллары, географик урыны, халкы, геройлары, күренекле кешеләре, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы турында мәгълүмат бирү. "Азнакай", "Азнакай тамчылары" китаплары белән танышу. Райондагы предприятиеләр турында әңгәмә. Районнан чыккан күренекле артистлар, язучылар, шагыйрьләр, аларның иҗаты белән танышу.

**<u>Практика:</u>** Район үзәгендәге Җиңү паркына, "Маяк" газета-сы редакциясенә, районның Туган як музеена, Боз сараена, "Дельфин" су- сәламәт-ләндерү үзәгенә, мәгърур Чатыр - тауга экскурсия. *Әдәби – музыкаль кичә "Шушы яктан, шушы туфрактан без...", Һөнәр сайлау кичәсе :"Дәрәҗәле һөнәр иясе Сез,Без дә Сездән үрнәк алабыз"*

**IV. Татарстан-минем республикам (20 сәгать)**.

**<u>Теория:</u>** ТР тарихы, географик урыны, символикасы, табигате, күренекле шәхесләре, шәһәрләре. Казан-чал тарихлы башкала. Алабуга-чор -дәверләр капкасы.

**<u>Практика:</u>** Казан шәһәренә багышланган "Йолдызлы сәгать"уены үткәрү. Тарихи шәһәрләргә читтән торып экскурсияләр. Күренекле шәхесләре турында әңгәмә ."Татарстан һәм татар халкы тарихы" конкурсында катнашу.*"Тамчы-шоу*

**Укыты-тематик планның эчтәлеге (2 нче уку елы)**

***I. Мин һәм минем гаиләм (18 сәгать)***

**<u>Теория:</u>** Гаилә тарихын өйрәнү.Шәҗәрә турында аңлатма.Нәсел шәҗәрәләренең ерак тарихыбызны өйрәнү өчен мөһим чыганак булуы. **<u>Практика:</u>** Шәҗәрә төзү үрнәкләре. Нәселнең географиясе, нәсел башлыгын эзләп табу. Гаиләдә электән сакланган хатларны туплау, хатлардагы мәгълүматларны файдалану. Нәселнең шөгыльләрен, һөнәрләрен өйрәнү.Укымышлы һәм озын гомерле кешеләре турында мәгълүмат җыю. Гаилә

традицияләре һәм аларны саклау. Һәр буынга сыйфатлама-характеристика язу -“Минем шәҗәрәм”. *“Шәҗәрәдә - гаиләм тарихы”- дәрес-конференция. Нәсел агачын төзү үрнәкләре.*

### *II. Туган ягым – Азнакаем ( 19 сәгать)*

**<u>Теория:</u>** Азнакайга нигез салыну. Исеме, риваятьләре, мәйданы, географик урыны, халкы, сулыклары, истәлекле урыннары, атамалары, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы белән танышу. Туган төбәк кешеләренең культурасы, гореф-гадәтләре.

**<u>Практика:</u>** Бәет, җырлар чыгаручы кешеләр белән очрашу. Һөнәрчеләр һәм аларның һөнәрләре турында мәгълүмат җыю, кул эшләреннән күргәзмә әзерләү,видеотасмага төшерү. Төрле оешмаларның тарихы. Хезмәт кешеләренең тормышын өйрәнү, төрле һөнәр ияләре белән очрашулар үткәрү. Бөек Җиңүнең 74 еллыгы уңаеннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш чоры балалары турында материаллар туплау, өйләрендә булу. Фәнни-тикшеренү эшләре башкару. Әфганстанда хәрби хезмәттә булучылар турында мәгълүмат туплауны дәвам итү. Мәктәп тарихын өйрәнү, ветеран укытучылар , чыгарылыш укучылары белән очрашулар үткәрү, мәктәп тарихын язуны дәвам итү күздә тотыла. Мәктәп музеена экскурсия. Төбәгебездәге күренекле кешеләрнең тормышларын өйрәнү, кылган гамәлләрен хөрмәтләү, яшь буынны шулар үрнәгендә тәрбияләү. *Истәлекле урыннарга сәяхәт.Чишмәләр,су буйларын күзәтү.*

### *III. Азнакаем - Чатыр таулы шигъри, җырлы, илһамлы төбәк...(44 сәг.)*

**<u>Теория:</u>** Районыбыз тарихы, мәйданы, авыллары, географик урыны, халкы, геройлары, күренекле кешеләре, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы турында мәгълүмат бирү. ”Азнакай”, ”Азнакай тамчылары” китаплары белән танышу. Райондагы предприятиеләр турында әңгәмә. Районнан чыккан күренекле артистлар, язучылар, шагыйрьләр, аларның иҗаты белән танышу.

**<u>Практика:</u>** Район үзәгендәге Җиңү паркына, ”Маяк” газета-сы редакциясенә, районның Туган як музеена, Боз сараена, “Дельфин” су- сәламәт-ләндерү үзәгенә, мәгърур Чатыр -тауга экскурсия. **<u>Әдәби кунакханә</u>** “Шушы яктан, шушы туфрактан без”
Һөнәр сайлау – җаваплы эш. Туган төбәгебездә дәрәҗәле һөнәрләр (телдән журнал)
“Дәрәҗәле һөнәр иясе Сез ,
Без дә Сездән үрнәк алабыз” (күренекле якташларыбыз - мактаулы һөнәр ияләре).
Шигырь - хикәяләр язу. Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау

### *IV. Татарстан - минем республикам (40 сәгать)*

**<u>Теория:</u>** ТР тарихы. Татарстанның символикасы. ТРның географик урыны.
Татарстанның табигате. ТР шәһәрләре . Республика шәһәрләре белән таныштыру. Казан-чал тарихлы башкала. Алабуга - чор - дәверләр капкасы.
“И Казан! Серле Казан!” Күренекле шәхесләр: язучылар, шагыйрьләр,
Җырчылар, артистлар. **<u>Практика:</u>** Музейга тематик экскурсия “Буыннардан буыннарга күчеп...”. Тарихи шәһәрләргә читтән торып экскурсия ясау. Башкалабыз Казанга багышланган “Йолдызлы сәгать” уены. Туган җирем – татар телле Татарстан (Туган тел турында...). Туган төбәк, туган җир, туган телебез турында иҗади эшләр дәресе.
“Татарстан һәм татар халкы тарихы” конкурсы
“Газиз дә син, кадерле дә, әй Туган җирем!”- ““Йолдызлы сәгать” уены

### *V. Туган төбәгем әдәбияты (34 сәгать)*

**<u>Теория:</u>** Илдус Гыйләҗев – җир шагыйре**.** Рөстәм Зәкуан “Җырым туса иде туган җирдә...” **.** Марсель Галиев – Чатыр тау данын еракларга яңгыраткан якташ язучыбыз**.**

Нур Әхмәдиев – шагыйрь һәм прозаик**.** Фәүзия Төхвә-туллина**.** Флёра Гыйззәтуллина шигырьләре – “тормышның үз авазы”.
Резедә Шәрипова – яраткан шагыйрәбез.Әнәс Кари –кыска иҗат гомерен балалар әдәбиятына багышлаган шагыйрь .Галия Сәетшина – авылга дан җырлаучы якташыбыз. Сәрвәр Хәнипова – туган җирнең матурлыгына, аның халкына дан җырлаучы укытучы-шагыйрә. Илмира Сәлахова – балачак шагыйрәсе. **Практика:** Әдәби сәхифә “Илдус Гыйләҗев шигъриятенең өч таҗы”. Туган төбәгебез шагыйрь – язучылары турында проектлар төзү, яклау. “Без шигырь яратабыз” шигырьләр уку бәйгес

***VI . Татар халкының бәйрәмнәре ( 12 сәгать)***

**Теория:** Татар халкының бәйрәмнәре. Дини бәйрәмнәр
Ел фасылларына бәйле милли бәйрәмнәр, йолалар, гореф-гадәтләр
Милли киемнәр. Татар хатын-кызларының милли киеме. Ир-атларның милли киеме. Милли киемнәрнең бизәлеше, төсләре.
**Практика:** “Нәүрүз” бәйрәме. Сабантуй- хезмәт туе

***VII . Шигырь язарга өйрәнәбез (10 сәгать)***

**Теория:** Шигырьдә ритм һәм рифма саклау кагыйдәләре. 2019 нчы ел Тукай премиясе лауреатлары. **Практика:** Күренекле шагыйрьләрнең шигырьләрен уку, шигырь төзелешен тикшерү. Газета - журналларда басылган шигырьләргә күзәтү. Төрле темаларга шигырьләр иҗат итү, аларны утырышларда уку, анализлау, әдәби тәнкыйть ясау. “Без –Тукай оныклары”

***VIII. Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый... ( 8 сәгать )***

**Практика:** Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый... (БВС ның 74 елллыгы ) – шәһәребезнең Җиңү паркына, Җиңү мәйданындагы мәңгелек ут монументына экскурсия.Экскурсоводлар белән индивидуаль эш.
“Үлемсез полк” акциясендә катнашуга әзерлек, катнашу

***IX. Газета-журнал укый беләбезме? (18 сәгать)***

**Теория:** Газета ничек ясала? Хәбәрчегә хас сыйфатлар. Минем яраткан газетам. Газета алдаганны яратмый. Газеталарга күзәтүләр. Хәбәри һәм аналитик жанрлар: корреспонденция- җәмәгатьчелек игътибарын проблемага юнәлтә. Мәкалә һәм аның төрләре: үтенеч, сорау, информация, бәяләмә, рәхмәт
**Практика:** Хәбәр язарга өйрәнәбез. Мәктәптә булган вакыйга яки факт турында язу. Репортаж-күзәтче жанр. Очрашулар, бәйрәмнәрдән репортажлар язу. “МАЯК” газетасы редакциясенә экскурсия

## 4 нче бүлек Планлаштырылган нәтиҗәләр

“Әдәби туган як” өйрәнү түгәрәгендә шөгыльләнгән бала **1 нче уку елында:**

- үз гаиләсе тарихына хөрмәт белән карый, горурлану хисләре кичерә;
- мөстәкыйль рәвештә ачышлар ясый;
- материал җыя, гомумиләштерә, мәктәп музеен тулыландыра;
- уеннар вакытында өйрәнгән материалны ныгыта;
- үз – үзендә патриотизм, туган якка мәхәббәт хисе тәрбияли;

- туган як әдәбияты,  тарихы буенча белемнәрен арттыра;

- эзләнү эше алып бара, материалны анализлый, системалаштыра, гомумиләштереп, нәтиҗәләр ясый;

- фәнни-тикшеренү эшләренә өйрәнә;

- үз – үзендә патриотизм, туган якка мәхәббәт хисе тәрбияләүне дәвам итә;

- туган төбәгенең тарихына, әдәбиятына, сәнгатенә  бәйле  күренекле шәхесләре белән горурлана.

"Әдәби туган як" өйрәнү түгәрәге программасын уңышлы үзләштергән укучы **2 нче уку елында:**

- мәктәптә яки сыйныфта үткәрелгән чара турында хәбәр яза;

- ритм һәм  рифманы иҗат эшендә дөрес итеп куллана;

- һәр эшендә пөхтәлеккә, язмаларының дөреслегенә ирешергә омтыла;
- сүзләрдән образ тудыра, художестволы чаралар ярдәмендә иҗат итә белә;

- үзе иҗат иткән шигырьне сәнгатьле итеп сөйли;

- хәзерге татар әдәби телендә аралаша һәм сәхнәдән торып сөйли белә;

- иҗади бәйгеләрдә катнаша.

## 5 нче бүлек Программаны тормышка ашыруның оештыру-педагогик шартлары

**Тормышка ашыру шартлары:** таләпләргә туры килеп яктыртылган укыту  кабинеты, укытучы өстәле белән урындыгы, укучылар өчен өстәлләр белән урындыклар, класс тактасы, ноутбук, проектор, экран, югары педагогик белемле педагог.

**Аттестация формалары**: шәҗәрәләр күргәзмәсе, әдәби очрашулар, тестлар, интеллектуаль бәйгелләр, дәрес – конференция**,** әдәби – музыкаль кичәләр.

**Белем нәтиҗәлелеген билгеләү формалары**: мактау кәгазләре, дипломнар, тест материаллары, сертификатлар, фотолар, мәкаләләр.

**Белемнәрне күрсәтә белү формалары**: иҗади эшләрне, проектларны яклау, бәйгеләрдә, фәнни – гамәли конференцияләрдә катнашу.

**Белем бирү процессын оештыру үзенчәлеге**: очно;

**Укыту процессын оештыру формалары:** индивидуаль, группалап, индивидуаль – группалы;

**Укытуны оештыру формалары**: әңгәмә,проектлар яклау, уен – бәйге, әдәби – музыкаль кичә,экскурсия, практик эш, мөстәкыйль эш, семинар.

**Педагогик технологияләр**:

- үстерелешле укыту;
- хезмәттәшлеккә корылган укыту технологиясе;
- коммуникатив технологияләр;
- проблемалы һәм өлешчә эзләнү технологияләре.

Педагогик технологияләр һәм методларны сайлау укучының шәхси сыйфатлары һәм универсаль уку күнекмәләрен үстерү максатыннан укытуны дифференциальләштерү и индивидуальләштерү кирәклегеннән чыгып билгеләнде.

**Укыту дәресләренең алгоритмы**

Укыту дәресенең алгоритмы-этаплар саны аның тибына һәм белем бирү процессының урынына, шулай ук педагог сайлаган урынга, үткәрү формасына бәйле. Әлеге программа кысаларында нигездә уку дәресенең 10 этабы кулланылырга мөмкин:

Оештыру этабы;

Тикшерү этабы;

Әзерлек этабы;

Белемнәрне актуальләштерү этабы;

Яңа материал буенча эш этабы;

Алынган белемнәрне, күнекмәләрен беренчел беркетү этабы,

Өйрәнелгән материалны кабатлау этабы;

Үткән материалны гомумиләштерү этабы;

Яңа белемнәрне, күнекмәләрне ныгыту этабы;

Физкультминутка яки релаксация этабы;

Контроль этап;

Йомгаклау этабы;

Рефлексия этабы;

Мәгълүмат этабы.

**Методик материал**: "ӘДӘБИ ТУГАН ЯК" өстәмә гомуми белем бирү гомуми үсеш программасы, фотосурәтләр, фотоальбомнар, музейда тупланган альбомнар, китаплар, истәлекләр, экспонатлар, карталар, әдәби китаплар, видеоязмалар, журналлар.

**Программаны тормышка ашыру юллары**

Түгәрәктә туган як әдәбияты һәм тарихы белән кызыксынган балалар шөгыльләнә. Программа үзенең эчтәлеге белән төбәк тарихын үткәннән алып бүген-гесенә кадәр үз эченә ала.Туган як тарихын өйрәнү юллары һәм методлары төрле: семинар, экскурсия, очрашулар, төрле уеннар, эзләнү –тикшеренү эшләре һ.б. Аларны үткәрү укучының яшеннән, әзерлек дәрәҗәсеннән, түгәрәк занятиеләренең максатыннан тора. Бигрәк тә экскурсияләр укучыларда зур кызыксыну уята. Укучыларның түгәрәк белән кызыксынулары артсын өчен, укытучы үткәрү формаларын чиратлаштырып барырга тиеш. Балалар мөстәкыйль рәвештә документаль чыганакларны өйрәнеп, тикшеренү эшләре алып барырга омтылалар. Тикшеренү эшләре укытучы җитәкчелегендә алып барыла. Эшне оештырган укытучы үзе дә, беренче-дән, төбәк тарихы буенча төп чыганакларны белергә тиеш. Икенчедән, үзе дә тикшеренү эше белән шөгыльләнергә, укучының эше белән кызыксынырга, өченчедән, туган як әдәбиятын, тарихын өйрәнү буенча класстан тыш эшләрдә оештыручы булырга тиеш.

Укучыларны бигрәк тә үзләренең күңелләренә якын булган, танышлары, якыннары катнашкан вакыйгалар, Азнакаебызның барлыкка килүе кызыксындыра. Шуңа да дәресләрендә тарихи вакыйга турында сөйләгәндә , бу вакыйганың безнең җирлеккә, авыл кешеләренә нинди мөнәсәбәте булуын аңлату кирәк.

Бу прогамма укучыларга туган төбәкнең тарихы , мәдәнияте, сәнгате, әдәбияты турында тирәнрәк аңларга, төрле формадагы эзләнү эшләренә - гади язмадан башлап,

фәнни-тикшеренү эшләренә кадәр - өйрәнергә мөмкинлек бирә. Программа буенча эшчәнлек нәтиҗәләре укучылар тарафыннан иҗади эшләр, реферат, фәнни-тикшеренү эшләре, презентацияләр һ.б. формасында тәкъдим ителә.

## 6 нчы бүлек Аттестацияләү формалары/контроль һәм бәяләү материаллары

**Аттестация формалары**: күзәтү, практик эш, мөстәкыйль эш, бәйге, әдәби – музыкаль кичә.

**Укыту нәтиҗәләре** видеоязма, иҗади эш, диплом, фотосурәт, фоторепортаж, презентация, эзләнү эше, проект яклау, әзер эш аша билгеләнә.
Укыту нәтиҗәләрен фәнни-практик конференциядә катнашу, иҗади эш яклауда, күргәзмәдә, конкурста, бәйрәмдә күреп була.

**Аттестация материаллары** кушымтада бирелгән.

## 7 нче бүлек. Әдәбият исемлеге

Программа төзегәндә кулланылган әдәбият:

1. Краеведение в школе. – Педагогическая энциклопедия, т.2.М., Советская энциклопедия,1965, с. 518-520.

2. Краеведческая программа. “Литературное краеведение”, составлена С.С.Кулаковой.

Өстәмә белем бирү педагогы өчен әдәбият:

3. В.Е.Туманов. Школьный музей-хранитель народной памяти.М., 2006.

4. Экология һәм табигатьтән файдалану. – 3 нче чыгарылыш. – Казан: Татполиграф, 1997. – 378 б.

5. А.С.Тайсин. Татарстан Республикасы географиясе. Гомуми урта белем мәктәбенең 8-9 класслары өчен уку ярдәмлеге. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2002 ел. – 230 б.

Әдәби туган як”түгәрәгендә шөгыльләнүче укучылар өчен әдәбият:

6. Азнакай тамчылары. – Казан: “Рухият” нәшрияты, 2000 ел. – 210 б.

7. Азнакай районы һәм шәһәре укучыларының көндәлеге.

8. “Азнакай”. – Казан: “Эксклюзив” нәшрияты, 2001. – 171 б.

9. Большая Советская Энциклопедия. – третье издание. – Москва: Издательство “Советская энциклопедия”, 1972. – стр. 606

10. Книга памяти о советских воинах, погибших в Афганистане.-т-2, Москва, Военное издательство, 1999

11. Гарифуллин В.Г. "Үткен каләм, үткер күз”. Казан: Тат. китап нәшр.,1995 – 165 б.

12. Низамов И.М. Матбугатның тәэсирле сүзе. / И.М.Низамов. казан: Тат.кит.нәшр., 1988. – 144 б.

13. “Мәйдан “журналы

14.”Мәгариф”журналлары

15. Музей материаллары.

16.Протащук И.Ю.Гаилә елъязмалары.Казан -2009.

17.Татарстан тарихы.Төп мәктәп өчен уку әсбабы.-Казан.-ТаРИХ, 2001

18.Хәтер.Татарстан Республикасы, Казан, Хәтер китабы нәшр.,1996.

19. Красная книга Республики Татарстан. – К., 1995.

20. Илдус Гыйләҗев “Назга сусау”

21. Рөстәм Зәкуан “Күңел тыкрыклары”

22. Марсель Галиев “Учымда тургай шәүләсе”, “Нигез”.

23. Нур Әхмәдиев “Күзгә күз”, “Яралы күк”, “Ак бишегем”, “Чакматаш”, “Чәкчәк”, “Алтын куллы кырмыска”.

24. Фәүзия Төхвәтуллина шигырьләре

25. Флёра Гыйззәтуллина шигырьләре

26. Резедә Шәрипова “Бүген бездә Сабантуй”

27. Әнәс Кари “Гөлбакча”, “Тамчы тамганда”

28. Галия Сәетшина “Җырларымда гомерем агышы”

29. Сәрвәр Хәнипова “Яшьлеккә сәяхәт”,

30. Илмира Сәлахова “Тылсым иле. Страна чудес”. Азнакай: Эшмәкәр СираевА.А.,2017. -64 б.

30. Илмира Сәлахова “Болытларда нинди сер бар?”. Казан: “Сүз”нәшрияты, 2015.- 32 б.

31. Гарифуллин В.Г. "Үткен каләм, үткер күз”. Казан: Тат. китап нәшр.,1995. – 165 б.

32. Низамов И.М. Матбугатның тәэсирле сүзе. / И.М.Низамов. казан: Тат.кит.нәшр., 1988. – 144 б.

33."Сабантуй”, "Көмеш кыңгырау”, "Йолдыз” газеталары, "Идел”, “Ялкын” журналлары.

34. Азнакай районының “Маяк” газетасы саннары

Кулланылучы интернет-чыганаклар:

http://gzalilova.narod.ru

http://www.tatmedia.ru/

http://sabantui.com

**В данном документе прошнуровано, пронумеровано и скреплено печатью**

26 (двадцать шесть) листов

**Директор МБОДО «ЦДТ г. Азнакаево»**

______________________ **Р.М. Хасанова**